ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» октябрь 2019 г. № 416

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 30.09.2009 ел, № 376 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 5 бүлекне, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 3 бүлекне, 2009 елның 4 сентябрендәге 06-62/5476 номерлы “Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем төзү турында” Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының хатын һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү сораулары буенча сорауларны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 30.09.2009 ел, № 376 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркем турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

4.9 пунктында “эшче төркем утырышы эшче төркем әгъзаларының гомуми саныннан кимендә *(2/3 или 1/2)* өлеше булса, хокуклы дип санала” сүзләрен “эшче төркем утырышы эшче төркем әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 1/2 өлеше булса, хокуклы дип санала” дип үзгәтергә.

2. Әлеге карар белән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча эшче төркемне таныштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**